**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
ЧЕРЕМШАНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

17.03.2026 **Чирмешән авылы** № 47

**2026 елга Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының «Лашман авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча гавами тыңлаулар уздыруны билгеләү хакында**

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Россия Федерациясенең 2025 елның 25 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законы, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советының 22.12.2021 №80 карары белән расланган Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районында гавами тыңлаулар (җәмәгать тыңлаулары) уздыру тәртибе турында нигезләмә нигезендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының «Лашман авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча гавами тыңлаулар үткәрүне билгеләргә.

2. Гавами тыңлауларны оештыручы составын-коллегиаль киңәшмә органын расларга:

- Җамалетдинов И.М. - Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе;
- Вилданов М.Г. - Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары;
- Җиһаншина Э.Б. - Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге башлыгы;
- Сабиров А.А. - Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисе;

- Фәттахов Р.Г. - Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Лашман авыл җирлеге башлыгы.

3. Гавами тыңлауларны оештыручыга гавами тыңлауларны җирле үзидарә турындагы, шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы кануннар нигезендә оештыруны һәм уздыруны тәэмин итәргә.

4. Гавами тыңлаулар үткәрү чорын – кызыксынучы затларга аларны үткәрү турында хәбәр иткән вакыттан алып гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә басылып чыккан көнгә кадәр билгеләргә. Гавами тыңлаулар үткәрү срогы проект басылып чыккан көннән алып бер айдан да артмый.

5. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы башкарма комитетына иҗтимагый фикер алышулар башлану турында Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 5.1 маддәсендә каралган тәртиптә хәбәр итәргә.

6. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

7. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары М.Г. Вилдановка йөкләргә.

Башкарма комитет
җитәкчесе И.М. Җамалетдинов